ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ТИМОШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

№7 08.02.2021

Иске Тимошкино авыл җирлеге башкарма комитетының
«Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»на
24.12.2018 ел, №12 карары белән расланган
(Иске Тимошкино авыл җирлеге башкарма комитетының
10.12.2019 ел, №8 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Федераль мәгълүмати адреслы система турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законга таянып, Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Иске Тимошкино авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2018 елның 24 декабрендәге 12 номерлы карарының 4 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

**- 2.5 пунктында: 4 пунктта** түбәндәге сүзләр өстәргә: «(бинага (төзелешкә) яисә корылмага адрес бирелгән очракта, шул исәптән төзелеш тәмамланмаган, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, аларны төзү өчен төзелешкә рөхсәт алу таләп ителми, күрсәтелгән бина (төзелеш), корылма урнашкан җир кишәрлегенә хокук билгели һәм (яки) хокук раслый торган документлар таләп ителми.)»;

**5 пунктчада:** «күчемсез мөлкәт объектларының кадастр паспортлары» сүзләрен «күчемсез мөлкәт объектлары турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр» сүзләренә алмаштырырга;

**6 пунктчада:** «адресация объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт һәм (яки)» сүзләрен «(әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә бинаны (төзелешне), корылманы төзү яки үзгәртеп кору өчен, төзелешкә рөхсәт алу таләп ителми торган очраклардан тыш) һәм (яки) адресация объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт булганда,» сүзләренә алмаштырырга;

**7 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:**

«адресация объекты булган күчемсез мөлкәт объекты турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;»

**«8» һәм «9» пунктчаларын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә: « адресация объекты булып торучы дәүләт кадастр исәбеннән алынган күчемсез мөлкәт объекты турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә; (әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адресация объектының адресын юкка чыгарган очракта); Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында адресация объекты булган күчемсез милек объекты буенча соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә (әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адресация объектының адресын юкка чыгарган очракта).».

Түбәндәге эчтәлекле **34_1 пунктын** өстәргә:

"Әлеге Кагыйдәләрнең 34 пунктындагы «б», «д», «з» һәм «и» пунктчаларында күрсәтелгән документлар, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне бирү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, яисә күрсәтелгән орган карары нигезендә үзенә буйсынган федераль дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан вәкаләтле орган рәсми сорау буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә гамәлдә булган федераль башкарма хакимият органы тарафыннан тапшырыла.»

- **1.5 пунктының 8 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:**
«адресация объектының идентификацион элементлары» - җир кишәрлекләре номерлары, башка адресация объектларының типлары һәм номерлары;»

**- 11 абзацында 2.5 пункты, 2.6 пункты:**

«34 пунктта сүзләрен «а», «в», «г», «е» һәм «ж» пунктчалары 34 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә: әлеге Кагыйдәләрнең 34 пунктындагы «а», «в», «г», «е» һәм «ж» пунктчаларында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) электрон имзасы белән раслана, аның төре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 21_1 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнә.

**1.5 пунктының 10 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерцияле булмаган берләшмәләрен урнаштыру территориясе» сүзләрен «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары

өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе»  сүзләренә алмаштырырга»;

2. **үз көчен югалткан дип санау**:

-Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты турында» 2015 елның 11 сентябрендәге 8 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл жирлеге башкарма комитетының «Иске Тимошкино авыл җирлеге территориясендә адресларны үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 11 сентябрендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»  2019 елның, 10 декабрендәге, 8 номерлы карары.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында. (http:pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Тимошкино авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: П.А.Мулеева